# УРЫП-ҖЫЮ КӨНДӘЛЕГЕ



## РЕСПУБЛИКАДА ДА АЛДЫНГЫ



**"Кызыл Шәрык-Агро" "ВостокЗернопродукт" ЯАҖ "Көнчыгыш Әлки" филиалы комбайнчысы Рәниф Гатин урак башланганнан бирле 1733 тонна ашлык суктырып алды. Елның-елында урып-җыюда район комбайнчылары арасында алдынгылар сафында баручы Рәниф Рәүф улы быелгы уракта бөтен республика күләмендә беренчеләр рәтендә. Урак батыры Р.Гатин үзенең "Лексион" комбайны белән көн саен ким дигәндә 1200 центнер икмәк суктыра.**

Г.ЯРУЛЛИНА.

–Әти, мин дә үскәч синең кебек комбайнчы булам, – ди кечкенә Рәниф комбайны янында казынган Рәүф абыйга. Ул елларда районның алдынгы механизаторы Рәүф Гатинны белмәгән кеше булмагандыр, мөгаен. Урып-җыю вакытында исеме район газетасы битләреннән төшми алдынгы комбайнчының.

Әтисенең тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге, үҗәтлеге улына да күчкән, күрәсең. Кечкенәдән әтисе янында техника тирәсендә кайнашкан, комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән Рәниф җиденче класстан соң инде үзе комбайн белән идарә итә башлый, яхшы гына күрсәткечләргә ирешә.

Менә 30 елга якын Рәниф Гатин туган ягы басуларында хезмәт куя. Авыл хуҗалыгы техникасын биш бармагыдай белә, оста идарә итә ул. Һәр елны уракның башыннан ахырынача комбайнда эшләп, югары күрсәткечләргә ирешә.

Хатыны Миләүшә белән алар ике малай үстерәләр. Олы уллары Рәдис Казан дәүләт аграр университетының механикалаштыру һәм техник сервис факультетында укый. Беренче курсны тәмамлап җәйге каникулга кайткан әнә.

Үткән елларда Рәдис әтисе янында комбайнчы ярдәмчесе булып эшләп йөргән, бу хезмәтнең җаваплылыгын да, авырлыгын да яхшы аңлаган. Ә бу җәйдә ул үзе мөстәкыйль рәвештә комбайнга утырган, әтисеннән калышмаска тырышып, ярышып эшли. Урак башыннан бирле Рәдис 866 тонна бөртек суктырып алган. Әтиле-уллы Гатиннар бүген икесе дә Алпар кырларында бодай суктыралар.

–Алла боерса, исән-сау укып бетергәч монда эшкә кайтырга җыенам,–ди Рәдис.

Мондый тырыш, уңган егетләр эшкә кайтам дип торганда авылларыбызның киләчәге өметле әле! Рәниф Гатин Ульяновск, Курск өлкәләре кырларында да эшләп кайткан. Кайда эшләсә дә хезмәтен җиренә җиткереп башкара ул. Хезмәттәшләре, җитәкчеләре дә аны мактап туя алмыйлар.

–Комбайнын ул энәсеннән җебенә кадәр белә, карап-кейләп, саклап эшләтә. Ватыла калса, үз машинасы белән запчастьләр алып кайтып шундук көйләп куя.

–Рәниф алыштыргысыз ул безнең. Хезмәтенең чын остасы, ышанычлы, кешелекле, ярдәмчел дә,–кебек сүзләрне байтак кешедән ишетергә туры килде.

–Әгәр язмышыгызны үзгәртү мөмкинлеге булса, нәрсәгә тезәтмә кертер идегез? – дип сорадым Рәнифтән.

–Берни дә үзгәртмәс идем. Язмышымнан, бүгенге тормышымнан мин бик канәгать. Башка эшкә дә чакырып караганнары булды. Әмма күңел мәнә шушы кырларга тарта. Шушы иркен басуларда гына мин үземне рәхәт хис итәм,–ди алдынгы комбайнчы.

Шушы кызу эш чорына туры килгән туган көнен дә Рәниф Гатин басуда, комбайн штурвалы артында үткәреп җибәргән. Хәер, рекордлы күрсәткечләргә ирешеп эшләп, ул бит туган көненә үзенә иң зур бүләк ясаган!

комбайнчылар ярышы

## УРАК БАТЫРЛАРЫ

### ИГЕННӘРНЕ СУКТЫРУ

*(Нью-Холланд, Лексион, Мега комбайннары)*

*Беренче графада – комбайнчыларның исем-фамилиясе, икенче – хуҗалык исеме, өченче – соңгы өч көндә суктырылган иген, дүртенче – урак башыннан суктырылган иген (тонналарда).*

| | | | |
|---|---|---|---|
| Гатин Мансур | Үзәк Әлки | 645 | 920 |
| Желтухин Игорь | Үзәк Әлки | 379 | 1013 |
| Ситдыйков Илфат | Үзәк Әлки | 375 | 869 |
| Җиһангиров Әсхәт | Үзәк Әлки | 348 | 752 |
| Гатин Рәниф | Көнчыгыш Әлки | 255 | 1733 |
| Латыйпов Ришат | Үзәк Әлки | 252 | 885 |
| Абасев Юрий | Үзәк Әлки | 191 | 711 |
| Севрикеев Юрий | Үзәк Әлки | 183 | 984 |
| Краснов Владимир | Хузангай | 145 | 1057 |
| Гатин Рәдис | Көнчыгыш Әлки | 133 | 866 |
| Шәмәрдәнов Илмир | Үзәк Әлки | 109 | 786 |

### ИГЕННӘРНЕ СУКТЫРУ

*(Акрос, Класс комбайннары)*

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мукусев Михаил | Хузангай | 175 | 1122 |
| Зиньков Артем | Хузангай | 175 | 1116 |
| Илюхин Вячеслав | Хузангай | 152 | 1087 |
| Шакин Александр | Хузангай | 138 | 1045 |
| Мукусев Артем | Хузангай | 137 | 1114 |

### ИГЕННӘРНЕ ТЕЗЕМНӘРГӘ САЛУ

**(МагДон комбайннары)**

*Беренче графада – комбайнчыларның исем-фамилиясе, икенче – хуҗалыклар исеме, өченче – урак башыннан теземнәргә салынган мәйдан (гектарларда).*

| | | |
|---|---|---|
| Нуретдинов Әмир | Хузангай | 220 |
| Морелев Вадим | Хузангай | 217 |
| Кашкаров Владимир | Хузангай | 209 |

### ИКМӘК ТАШУ

*(«КамАЗ» автомобильләре)*

*Беренче графада – шоферларның исем-фамилиясе, икенче – хуҗалык исеме, өченче – урак башыннан бирле басудан ташыган икмәк (тонналарда).*

| | | |
|---|---|---|
| Ермолаев Николай | Хузангай | 3360 |
| Шапеев Евгений | Хузангай | 3247 |

куркыныч чир

## АФРИКА ЧУМАСЫ ДУҢГЫЗЧЫЛЫКНЫ ЮК ИТӘ

**Дуңгызларда Африка чумасы чире буенча Россиядә киеренке хәл саклана. Ел башыннан бирле бу куркыныч чир илнең җиде төбәгендә теркәлде. Дистәләрчә терлекчелек объектлары яндырылды, уннарча мең дуңгызлар юк ителде, хуҗалыкларга бик зур икътисадый зыян салынды. Дуңгызларның чума белән чирләвенең соңгы очрагы күптән түгел Тверь өлкәсенең Калинин районында булды.**

**Бу мәкерле һәм яман авыруның республика территориясенә үтеп керүенә юл куймас өчен җитди һәм кырыс чаралар күрелә. Безгә дә әлеге мәсьәләдә сак һәм уяу булу зарур.**

Р.ГАЛЛӘМОВ,
район дәүләт ветеринария берләшмәсе начальнигы.

Профилактика максатларында дуңгызларны ирекккә чыгарып йөртү һәм аларга тиешенчә кайнатылмаган ризык калдыкларын ашату тыела. Малларны тиешенчә тукландырырга һәм карарга, аларга яхшы санитар шартлар тудырырга кирәк. Хайван авырып китсә, аны ветеринария белгеченә күрсәтмичә һәм диагноз куймыйча суярга да, юк итәргә дә ярамый. Хуҗалыкларда дуңгызларга классик чума чиренә каршы планлы профилактик вакциналарны вакытында ясарга кирәк.

Дуңгызчылык продукциясен стационар сәүдә предприятиеләрендә һәм базарларда – ит ветеринар-санитар экспертиза үткән урыннарда гына сатып алырга ярый. Продукциянең һәр төрендә җитештерүче предприятиенең маркировкасы һәм упаковкасы булырга тиеш. Киркәле мәгълүматлары булмаган дуңгызчылык продукциясен һич тә сатып алырга ярамый! Санкцияләнмәгән сәүдә урыннарында (рәхсәтсез оешкан базарларда) ит сатып алу бигрәк тә куркыныч. Гомумән, рәсми билгеләнмәгән урында дуңгыз ите сату катгый тыела. Дуңгыз итен һәм аның башка продуктларын ризыкка кулланыр алдыннан җентекләп термик эшкәртү (кайнату) таләп ителә.

Дуңгызларның яисә кабаннарның Африка чумасына охшаш билгеләрдән үлү очраклары була икән, бу хакта кичекмәстән дәүләт ветеринария хезмәте белгечләренә хәбәр итсәгез иде.

Африка чумасының билгеләре нинди соң? Чир йоктырган хайван кәефсезләнә, арткы аяклары хәрәкәтсез кала, колакларында, авыз тирәсендә, корсагында, аяк араларында һәм муенының аскы өлешендә кызыл-шәмәхә төстәге таплар барлыкка килә. Хайванның үпкәсе ялкынсыну билгеләре дә озак көттерми: ул еш һәм өзек-өзек сулый, кайчагында ютәлли. Дуңгызның ашкайнату системасы да бозыла: эче кибә, тизәге лайла белән капланган була. Терлекнең тән температурасы 40,5-42 градуска кадәр күтәрелә, ул күбрәк ятып тора, сулышы кысыла, ә 24-72 сәгатьтән соң үлә. Дуңгыз 24-48 сәгать комада да булырга мөмкин, бу очракта аның температурасы нормадан түбән төшә, һәм 4-10 көннән терлек үлә.

Бүген районыбыз хуҗалыкларында 10 мең баштан артык дуңгыз исәпләнә. Аларның 7760 башы – җәмәгать секторында, 2485 башы – 27 торак пунктта шәхси хуҗалыкларда.

Җәйгә кергәч күп авылларда дуңгызларны ирекккә чыгарып йөртә башлыйлар. Ә бит үз иркендә йөргән хайваннар фермалар, азык базалары территорияләренә үтеп керә, кырларда, урманнарда йөри. Кыскасы, караучысыз калган дуңгызларның кабаннар белән контактка керүе дә бик мөмкин.

Шәхси хуҗалыкта асраучы дуңгызларның иректә йөрүе бигрәк тә Түбән Колчурино, Юксыл, Хурада, Иске Тахтала, Каракүл, Югары Кәчи авылларында күзәтелә.

Ә бит үз иркендәге хайваннарның теләсә нинди инфекция, шул исәптән Африка чумасын да йоктыру ихтималы бар. Моның нәтиҗәләре исә бик яман булачак.

Дуңгызларга нинди куркыныч янавын аңлап, авыл халкы аларны бары тик ябып асрау чарасын күрсен иде. Авыл җирлекләре җитәкчеләре дә бу мәсьәләне күз уңында тотарга, дуңгызларны урамга, кырга чыгарып җибәрүнең һәр очрагын исәпкә алырга тиешләр.

Африка чумасы – бик куркыныч чир. Ул безнең җирлеккә үтеп кермәсен дисәк, барлык саклык чараларын төгәл үтик.


## САЛАМ САТЫЛА

«Хузангай» кооперативы халыкка салам сата.
Белешмәләр өчен **телефон: 73-4-01.**



### Икътисад, идарә һәм хокук институтының (Казан шәһ.) Чистай филиалы

*2012-2013 уку елына түбәндәге юнәлешләр буенча укучылар кабул итә:*

-Психология- педагогика белеме;
-Икътисад;
-Юриспруденция;

**Көллияткә**:
-Хокук һәм социаль тәэминатны оештыру;
-Икътисад һәм бухгалтерлык исәбе (тармаклар буенча);
-Кунакханә сервисы;
Уку сроклары:
-9 кл. базасында – 2 ел 10 ай;
-11 кл. базасында – 1 ел 10 ай;
-Урта һөнәри белем һәм югары һөнәри белем базасында – 3 ел.
Укуны тәмамлаганнан соң дәүләт үрнәгендәге диплом бирелә.
Адрес: Чистай шәһ., Җиңүнең 40 еллыгы ур., 32ж, "Икътисад, идарә һәм хокук институты" тукталышы, **тел.: 8(843-42) 4-04-11,**
e-mail:office@chs.ieml.ru, сайт: www.ieml.ru.
Кабул итү комиссиясенең эш вакыты:
Дүшәмбе-җомга 8.00 дән 18.00 гә кадәр,
Шимбә 9.00 дән 15.00 гә кадәр,
Якшәмбе 9.00 дән 13.00 гә кадәр.
Лицензия: ААА сериясе № 001329, теркәлү №1384 (16.05.2011 ел), Мәгариф һәм фән өлкәсенә күзәтчелек итү буенча федераль служба тарафыннан бирелгән.
Аккредитация турында таныклык: серия ВВ 000116 (15.12.2009 ел).
*Реклама.*